Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Келәнче авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

« 20 » сентябрь 2019 ел № 113

Келәнче авыл җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында

2002 елнын 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның гомуми принциплары” турындагы 131 номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум ” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авылы башкарма комитетының 20 сентябрь 2019 елда чыккан 27 номерлы “Җирле референдум үткәрү ” карары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советының 20 сентябрь 2019 елда чыккан 112 номерлы “Җирле референдум үтрәрү ” карары нигезендә,

Келәнче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Келәнче авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 2019 елның 17 ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәләне расларга:

2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, көндезге уку рәвеше буенча укучы студентлардан кала һәр кешедән 500 сум үзара салым кертү белән килешәсезме, һәм җыелган акчаларны, киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә билгеләнгән эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

- чүп үләннәрен чабу (җәйге-көзге чорда);

- суүткәргеч һәм су чыганакларын ремонтлау;

- Бәки авылы зиратына якын килү юлларын төзекләндерү;

- авыл эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- тукталыш павильонын ремонтлау;

- вакытлыча каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту.»

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур.,

шулай ук “Идел таңнары” газетасында бастырырга һәм мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге”
Советы рәисе Д.А. Кадыров